| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>СОВЕТ<br>БУИНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БУА<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>СОВЕТЫ |
|---|---|---|

| РЕШЕНИЕ | | КАРАР |
|---|---|---|
| | Буа шәһәре | |
| 28 май 2021 ел | | № 5-12 |

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыру тәртибе һәм шартлары турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Дәүләт мөлкәтен һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль законнар нигезендә Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Советы

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Советының 2017 елның 15 сентябрендәге 19-24 номерлы «Хосусыйлаштырылган торак урыннарын Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы милкенә тапшыру тәртибе турында нигезләмә хакында»гы карары белән расланган Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыру тәртибе һәм шартлары турында нигезләмәгә (алга таба - Нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1.1. 2 бүлек:

2.1 пунктын түбәндәге редакциядә үзгәртергә һәм бәян итәргә:

«2.1. Муниципаль мөлкәтне сатып алучылар теләсә нинди физик һәм юридик затлар булырга мөмкин, түбәндәгеләрдән тыш:

дәүләт һәм муниципаль унитар предприятиеләр, дәүләт һәм муниципаль учреждениеләр;

устав капиталында Россия Федерациясе, Россия Федерациясе субъектлары һәм муниципаль берәмлекләр өлеше, әлеге Федераль законның 25 статьясында каралган очраклардан тыш, 25 проценттан артыграк булган юридик затлар;

дәүләт яисә территория теркәлү урыны булып торучы, Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан раслана торган, салым салуның ташламалы салым режимын бирүче һәм (яисә) финанс операцияләре (офшор зоналары) уздырганда мәгълүматны ачуны һәм тапшыруны күздә тотмаган дәүләтләр һәм территорияләр исемлегенә кертелгән һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртиптә үзләренең файда алучылары, бенефициар хуҗалары һәм контроль итүче затлар турында мәгълүмат ачуны һәм бирүне гамәлгә ашырмаган юридик затлар;

«Контроль итүче зат» төшенчәсе «Ил оборонасын һәм дәүләт иминлеген тәэмин итү өчен стратегик әһәмияткә ия хуҗалык җәмгыятьләренә чит ил инвестицияләрен гамәлгә ашыру тәртибе турында» 2008 елның 29 апрелендәге 57-ФЗ номерлы Федераль законның 5 статьясында да кулланыла. «Файда алучы» һәм «бенефициар хуҗа» төшенчәләре «Җинаять юлы белән алынган керемнәрне легальләштерүгә (юуга) һәм террорчылыкны финанслауга каршы тору турында» 2001 елның 7 августындагы 115-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясында күрсәтелгән мәгънәләрдә кулланыла кулланыла.

Әлеге пунктта билгеләнгән чикләүләр үз белдекләре белән төзелмәгән һәм муниципаль милеккә караган җир кишәрлекләрендә урнашкан күчемсез милек

объектлары милекчеләренә әлеге җир кишәрлекләрен милекчеләре тарафыннан сатып алганда кагылмый.»;

1.2. 4 бүлек:

4.14 пунктын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.14. Муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыруны мәгълүмати тәэмин итү дигәндә хосусыйлаштыру турындагы мәгълүматтан затларның чикләнмәгән даирәсеннән иркле файдалана алу мөмкинлеген булдыруга юнәлдерелгән һәм «Интернет» челтәрендә муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыруның фаразлау планнары (программалары), муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру шартлары турындагы карарлар, муниципаль мөлкәтне сату турында һәм аны сату йомгаклары турындагы мәгълүмати хәбәрләр, муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру нәтиҗәләре турында еллык хисаплар урнаштыруны үз эченә алган чаралар аңлашыла.»;

1.3. 6 бүлек:

6.5 пункты.:

3 нче абзацның 1нче җөмләсен төшереп калдырырга;

6.9 пунктын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6.9. Ачык ( гавами) тәкъдим ярдәмендә сатуда катнашучыны җиңүче дип тану турында хәбәрнамә, җиңүчегә ачык ( гавами) тәкъдим ярдәмендә сатуга йомгак ясау көнендә гавами тәкъдим аша җибәрелә.».

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://buinsk.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырылырга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Буа муниципаль районы башлыгы,
Совет рәисе Р.Р. Камартдинов